СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 10-6 от «26» марта 2021 г.

2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы турында

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру максатында, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымтага нигезләнеп расларга.

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы» муниципаль казна учреждениесенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе
А.П.Иванов

000021

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Советының
26.03.2021 № 10-6 карарына
кушымта

2021-2023 елларга Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен
хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)

1 бүлек. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру өлкәсендә сәясәтне тормышка ашыруның төп юнәлешләре һәм бурычлары

2020-2021 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Көндәшлекне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру мәсьәләләрен җайга салучы башка норматив-хокукый актлар, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 октябрендә 10-35 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру турында Нигезләмә нигезендә эшләнгән.

Мамадыш муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыруның төп бурычы Мамадыш муниципаль районы җирле үзидарә органнары функцияләрен (вәкаләтләрен) һәм бурычларын тәэмин итү өчен файдаланылмый торган һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнмәгән муниципаль милекне хосусыйлаштыру хисабына муниципаль милек структурасын оптимальләштерү.

Муниципаль милекне хосусыйлаштыру программасы түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдереләчәк:

- тулаем алганда, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисады һәм аерым хуҗалык итүче субъектларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру;
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы бюджетына муниципаль милекне хосусыйлаштырудан планлаштырылган барлык керемнәрнең дә үз вакытында һәм тулаем керүе;

- муниципаль милекне хосусыйлаштырудан кергән акчалар хисабына җирле бюджетны тулыландыру;
- Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы икътисадын һәм аның инфраструктурасын үстерү өчен инвестиция чараларын җәлеп итү;

2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) гамәлдә булу срогы дәвамында аңа Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карары нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертелә ала.

Ел дәвамында хосусыйлаштырылмаган муниципаль милек объектлары киләсе елга фараз планына кертелә.

2 бүлек. 2021-2023 елларда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль милек объекты исемлеге һәм характеристикасы

2021-2023 елларга хосусыйлаштыру программасы буенча түбәндәге муниципаль милекне хосусыйлаштыру күздә тотыла:

| № п/п | Исеме | Адресы һәм урнашу урыны | Хосусыйлаштыру ысулы | фаразланган вакыты | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге белән Гараж (16:26:030201:287) | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Кече Сон авылы, Гагарин ур.,12 А й. | ачык аукцион | 2 квартал 2021 | |
| 2 | «Nissan Teana 2/3 LUXURI» маркалы автомобиль Госномер 0639МО 116 RUS Идентификацион номеры (VIN) JN1BAUJ31U0001576 | ТР, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 3 квартал 2021 | |
| 3 | LADA 210740LADA2107 автомобиль, Госномер Н200УУ, VIN XTA210740B3088201 | ТР, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2021 | |
| 4 | Автомобиль «Hyundai Sonata»,идентификация номеры (VIN) X7MEM41HP7M027 | ТР, Мамадыш ш., М.Җәлил ур, 23/33 й. | ачык аукцион | 4 квартал 2021 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 935 | | | | |
| 5 | Автомобиль BMW 750, идентификация номеры (VIN)WBAKC81060 CY67556 | РТ, г. Мамадыш, ул. Карла Маркса, 18/23 | ачык аукцион | 2 квартал 2022 | |
| 6 | «Hyundai NF Sonata» маркалы автомобиль, идентификация номеры (VIN)KMHEU41AP9 A667014 | РТ, г. Мамадыш, ул. Карла Маркса, 18/23 | ачык аукцион | 2 квартал 2022 | |
| 7 | «Fiat Albea» маркалы автомобиль, Госномер О252МО 116RUS, идентификация номеры (VIN) XU3178000BZ14456 0 | ТР,Мамадыш муниципаль районы, Җөри, Мәктәп ур., 2 й. | ачык аукцион | 2 квартал 2023 | |
| 8 | Абаган причалы (16:26:340249:0:3) | ТР, Мамадыш муниципаль районы, Мамадыш, Нократ елгасының уң як яры Абаган территориясе | ачык аукцион | 4 квартал 2023 | |

## Глава 3. Муниципаль милекне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

Хосусыйлаштыру программасын тормышка ашыру, шул исәптән хосусыйлаштыру ысулларын һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыруның башлангыч бәясен үз эченә алып, аукцион үткәрү юлы белән sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштырылачак.

Әлеге программада каралган хосусыйлаштыру шартлары турында Карар кабул итү муниципаль милекне хосусыйлаштыру максатларын һәм бурычларын тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк.